**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**"АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ"**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

| **"КАРАЛДЫ"** | **"КИЛЕШЕНДЕ"** | **"РАСЛАНДЫ"** |
|---|---|---|
| МБ житәкчесе | «2 нче Алексеевск УГББМ" МБГБУ директор урынбасары | «2 нче Алексеевск УГББМ" МБГБУ директоры |
| ______Замалиева И.Х | ______Ягудина Л.Р. | ______Липлянина Л.Н. |
| МБ утырышы беркетмәсе №__1__ 25 август 2016 ел | __27__ август 2016 ел | ______номерлы боерыгы ______ август 2016 ел |

**Татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Замалиева Илсөяр Хәнифовнаның**

**4 "А" сыйныфы өчен татар теле һәм әдәби укудан**

**эш программасы**

Педагогик совет утырышында каралды
__1__номерлы беркетмә
__31__ август 2016 ел

2016-2017 уку елы

## I.<u>Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре</u>

**Сыйныф** 4А сыйныфы (татар төркеме) татар теле һәм әдәби уку

**Сәгать саны:** 136 сәгать, атнага 4 сәгать

Планлаштырылган контроль дәресләр 5, зачетлар-1, тестлар-2

Административ контроль дәресләр 1 с.

- **Дәреслек :** Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова. Татар теле. Рус телендә белем бирүче дүртьеллык башлангыч мәктәпнең 4 нчы сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен). Казан.Мәгариф. 2009;

Эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:

1.Программа: "Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары" (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. "Мәгариф" нәшрияты, 2010)

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе "Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе"нең төп гомуми белем бирү баскычында гомуми башлангыч белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе "Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе"нең 2016-2017 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел).

**4 нче сыйныф укучыларының белем, осталык һәм күнекмәләренә төп таләпләр**

- 4 нче сыйныф ахырында укучыларда төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү күнекмәләре булдыру, аларның сүзлек байлыгын арттыру.
- Сүзләрнең тамырын һәм кушымчаларын табу. Төрле сүз төркемнәрен (исем, сыйфат, фигыльләрне) ясаучы кушымчаларны күрсәтү.
- Мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларны билгеләү. Укытучы тәкъдим иткән сүзләрнең төзелешен тикшерә белү.
- Исемнәрне килеш һәм тартым белән төрләндерү. Исемнәргә морфологик анализ ясау күнекмәләре булдыру (уртаклык яки ялгызлык булуы, берлектә яки күплектә килүе, килеше, тартым белән төрләнүе-төрләнмәве, нинди җөмлә кисәге булып килүен күрсәтү).
- Сыйфатларның төрле дәрәҗә формаларын ясау (гади, чагыштыру, артыклык һәм кимлек). Дәреслектәге һәм укытучы тарафыннан бирелгән сыйфатларның төрле дәрәҗә формаларын ясап, алар белән җөмләләр төзү.
- Микъдар һәм тәртип саннарын билгеләү, аларны сөйләмдә дөрес куллану.
- Тартым алмашлыкларын телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану.
- Боерык фигыльләрне зат-сан белән төрләндерү, хикәя фигыльләрнең барлык заманнарын зат-сан белән төрләндереп, аларны телдән сөйләмдә, изложение һәм сочинение язганда дөрес куллану.

- Җөмләнең баш кисәкләрен табып, аларның нинди сүз төркеме белән белдерелүенә мисаллар әйтү, укытучы күрсәткән (яки мөстәкыйль рәвештә укучы үзе тапкан) әдәби текстан баш кисәкләрне күрсәтү.
- Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану.
- Җөмләнең иярчен кисәкләреннән аергычның сыйфат, сан белән белдерелүен күрсәтү. Тиңдәш кисәкләрне билгеләү, алар янында җыючы һәм каршы куючы теркәгечләрне куллану. Җөмләгә синтаксик анализ ясау күнекмәләре булдыру (ия, хәбәр, аергыч, тиңдәш кисәкләрне күрсәтә алу).
- Эндәш сүзләрне иядән аеру, алар янында тыныш билгеләрен дөрес кую.

60—70 сүздән торган текст буенча изложение язу. Дәрестә өйрәнелгән (яки укытучы тәкъдим иткән) темага 40—55 сүздән торган сочинение язу. Сүзлек диктантының якынча күләме — 12—16 сүз. 50—65 сүздән торган контроль диктантлар яздыру.

***Укучыларның сөйләм эшчәнлегенә караган таләпләр:***

***1. Тыңлап аңлау:***

- укытучының (сыйныфташның) өйрәнгән материалга нигезләнгән сөйләмен тыңлап аңлау;
- текстны тыңлаганнан соң, төп фикерне башкаларыннан аера белү;
- татарча сөйләмне тыңлап, сүз һәм җөмлә чикләрен билгеләү;
- текстны тыңлап аңлагач, аңа исем бирү;
- ишеткән сөйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.

***2. Сөйләү:***

- укытучы тәкъдим иткән, программада каралган темалар буенча әңгәмә кору;
- диалогта катнашу;
- текстның эчтәлеген сөйләү;
- рәсем яки план нигезендә сөйләү;
- укыганның эчтәлеген сораулар нигезендә сөйләү;
- татар теленә хас булган эндәшү, мөрәҗәгать итү сүзләрен куллану.

***3. Уку:***

- хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне)сәнгатьле итеп уку;
- кыска сүзләрне — тулы килеш, озын сүзләрне иҗекләп **уку;**
- балалар өчен нәшер ителгән китаплар, газета-журнал-ларны, әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес, йөгерек һәм аңлап уку;
- укыган текстның төп фикерен аңлатып бирү;
- этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны аңлап уку;
- текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсенә төшенү;
- текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү;

***4. Язу:***

- бирелгән темага (татар язучылары, композиторлары, рәссамнары һ. б. турында) сочинение язу;
- орфографик күнегүләрдән соң тыныш билгеләре булган диктантлар язу;
- план нигезендә изложение язу;
- татар этнокультурасына караган сүзләр кертеп, җөмләләр язу;
- үзең, гаилә, мәктәп турында кечкенә хикәяләр яки котлау кәгазьләре язу.

## Укытуның предмет, метапредмет, шәхси нәтиҗәләре

***Шәхси нәтиҗәләр:***

1. Туган илгә карата шәхси караш булдыру
2. Чын кеше сыйфатлары булдыру
3. Мөстәкыйльлелек һөм җаваплылык үстерү
4. Этик хисләр, мөлаемлылык үстерү
5. Рухи-әхлакый идеалларына китерү
6. Олылар белән хезмәттәшлек
7. Аралашу культурасы күнекмәләре

***Метапредмет нәтиҗәләр:***

1. Аң - белем үстерү

2. Проблемаларны мөстәкыйль рәвештә таба алу
3. Эзләнү юлларын һәм нәтиҗәләрен ачыклау
4. Логик фикерләү:чагыштыру, синтез, анализ ясый белү
5. Конфликтлы ситуацияләрдән чыгу юлын табу
6. Укучыларның образлы, логик фикерләвен үстерү

***Предмет нәтиҗәләр:***

1. Россиядә күп милләт халыкларының төшенчәсен бирү
2. Татар теленең төп төшенчәләр буенча башлангыч белем ( фонетик, лексик, грамматик)
3. Татарча югары сөйләм культурасы формалаштыру
4. Туган телнең орфоэпик, лексик, грамматик төшенчәләре
5. Сүз турында башлангыч төшенчәләр формалаштыру
6. Уку, язу гамәлләре формалаштыру
7. Сүзгә фонетик анализ ясый белү

***Универсаль уку гамәлләре формалаштыру:***

***Танып белү универсаль уку гамәлләре:***

1. Дәреслектә ориентлаша белү
2. Шартлы билгеләрнең телен белү
3. Рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү
4. Төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру
5. Материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү
6. Дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү

***Регулятив универсаль уку гамәлләре:***

1. Кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу
2. Гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау
3. Үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү
4. Тормыш тәҗрибәсен куллану
5. Эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү

***Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:***

1. Дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү
2. Үз уңышларын/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү
3. Үз мөмкинлекләреңне бәяләү
4. Үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру
5. Мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)

***Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:***

1. Тормыш тәҗрибәсен куллану
2. Күршең белән хезмәттәшлек итү
3. Үз фикереңне һәм позицияңне формалаштыру
4. Уртак эшчәнлеккә һәм гомуми чишелешкә килү
5. Партнёрның нәрсәне белүен һәм күрүен, нәрсәне белмәвен һәм күрмәвен исәпкә алып, аңлаешлы сөйләм төзү, сораулар бирү
6. Партнёрның эш-гамәлләрен контрольгә алу;
7. Сөйләмнең диалог формасын үзләштерү.

4 нче сыйныфны тәмамлаганда башлангыч сыйныф укучылары татар теленнән түбәндәге белем һәм күнекмәләргә ия булырга тиеш:

Төрле типтагы сүзлекләр белән эшләү.

Сүзләрнең тамырын, кушымчаларын һәм нигезен табу. Төрле сүз төркемнәрен ясаучы кушымчаларны күрсәтү.

Укытучы тәкъдим иткән сүзләрнең төзелешен тикшерә белү.

Исемнәрне килеш һәм тартым белән төрләндерү. Исемнәргә морфологик анализ ясау (уртаклык һәм ялгызлык исемнәр, аларның берлектә яки күплектә килүе, килеше, тартым белән төрләнү-төрләнмәве, нинди җөмлә кисәге булып килүе)

Сыйфатларның төрле дәрәҗә формалары (гади, чагыштыру, артыклык, кимлек). Дәреслектә һәм укытучы тарафыннан бирелгән сыйфатларның төрле дәрәҗә формаларын ясап, алар белән җөмләләр төзү.

Микъдар һәм тәртип саннарын билгеләү. Аларны сөйләмдә дөрес куллану.

Тартым алмашлыкларын телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану.

Боерык фигыльләрне зат-сан белән төрләндерү, хикәя фигыльләрнең барлык заманнарын зат – сан белән төрләндереп, аларны телдән сөйләмдә, изложение һәм сочинение язганда куллану.

Җөмләнең баш кисәкләрен табып, аларның нинди сүз төркеме белән белдерелүенә (иянең исем яки зат алмашлыгы, хәбәрнең хикәя яки боерык фигыль, тартым алмашлыгы белән) мисаллар әйтү, укытучы яки мөстәкыйль рәвештә укучы үзе тапкан әдәби текстан баш кисәкләрне күрсәтү.

Җыйнак һәм җәенке җөмләләрне телдән һәм язма сөйләмдә дөрес куллану.

Җөмләнең иярчен кисәкләреннән аергычның сыйфат, сан белән белдерелүен күрсәтү. Тиңдәш кисәкләрне билгеләү, алар янында җыючы һәм каршы куючы теркәгечләрне куллану. Җөмләгә синтаксик анализ ясау ( ия, хәбәр, аергыч, тиңдәш кисәкләрне күрсәтә алу)

Эндәш сүзләрне иядән аеру, алар янында тыныш билгеләрен дөрес кую.

25-35 сүздән торган текст буенча изложение язу. Дәрестә өйрәнелгән яки укытучы тәкъдим иткән темага 20-25 сүздән торган сочинение язу. Сүзлек диктантының якынча күләме – 12-16 сүз. 30-35 сүздән торган контроль диктантлар яздыру.

## II.Укыту предметының эчтәлеге

| № | Төп темалар | Сәг. | Белем һәм күнекмәләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 1-3 сыйныфларда үткәннәрне кабатлау. | 20 | авазлар һәм хәрефләр; сузык һәм тартык авазлар; татар һәм рус телләренең икесендә дә булган, әмма әйтелеше белән татар телендә аерылып торган авазлар; сүзлекләр турында белешмә, тамыр һәм кушымчаларның үзенчәлекләре; исем; фигыль; сыйфат; җөмләнең баш кисәкләре; |
| 2 | Морфология. | 30 | - исем, исемнәрнең килешләр, тартым белән төрләнеше;<br>сыйфат, дәрәҗә формалары;<br>- сан, саналмышның кулланылу үзенчәлекләре;<br>- алмашлыклар, тартым, күрсәтү алмашлыклары;<br>- фигыль, боерык фигыльләр, үткән һәм киләчәк заман хикәя фигыльләр, барлык заман формаларын зат-сан белән төрләндерү;<br>- бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр |
| 3 | Синтаксис | 22 | - сүзтезмә һәм җөмлә;<br>- җөмләнең баш кисәкләре;<br>- җыйнак һәм җәенке җөмләләр;<br>- җөмләнең иярчен кисәкләре;<br>- җөмләнең тиңдәш кисәкләре;<br>- эндәш сүзләр |
| 7 | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 25 | |

## III. Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру

| № | Дәрес темасы | Уку эшчәнлеге төре | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Халык авыз иҗаты әсәрләре | Аңлап уку күнекмәләре булдыру китап белән эш схема белән эшләү | 2.09 |
| 2 | Тартык авазлар | Тартык авазлар классификациясен искә төшерү, татар телендә генә кулланыла торган тартык авазларның дөрес әйтелеше өстендә эшләүгә күнегүләр | 309 |
| 3 | Әкиятләр. “Җил арба” әкияте | Әкият белән танышу, сорауларга җавап бирү. План төзү | 5.09 |
| 4 | Ъ, ь билгеләре | Ъ, ь билгеләренең дөрес кулланылышын аңлау | 6.09 |
| 5 | “Җил арба” әкияте | Әкият белән танышу, сорауларга җавап бирү. | 9.09 |
| 6 | Сүзләргә фонетик анализ ясау | Фонетик анализ ясау күнекмәләрен камилләштерү | 10.09 |
| 7 | Мифлар. “Җил иясе”, “Тургай һәм Кояш” мифы | Укыган текстның мәгънәсен аңлау | 12 |
| 8 | Кереш диктант | | 13.09 |
| 9 | Фатих Әмирханның “Ай өстендә Зөһрә кыз” әкияте | Язучының тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат алу. Әкият белән танышу дәреслек. | 16 |
| 10 | Тәрҗемә итү күнегүләре | Русчадан татарчага тәрҗемә итү күнегүләре | 17.09 |
| 11 | Фатих Әмирханның “Ай өстендә Зөһрә кыз” әкиятен өйрәнүне йомгаклау | Сәнгатьле уку. Сүзлек байлыгын арттыру. Кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләү. | 19 |
| 12 | Тамыр һәм кушымча | Сүзләрне тамыр һәм кушымчаларга дөрес таркату күнекмәләре | 20.09 |
| 13 | Бәетләр. “Сак-Сок” бәете | Аңлап уку күнекмәләре булдыру | 23 |
| 14 | Исем ясаучы | Исем ясаучы кушымчаларны | 24.09 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кушымчалар | дөрес куллану | |
| 15 | Б.с.ү. Туган якның серле табигате. Бүлекне кабатлау | Күзгә матурлыкны күрә, соклана белү хисе тәрбияләү | 26 |
| 16 | Сыйфат ясаучы кушымчалар | Сыйфат ясаучы кушымчаларны дөрес кулланута схемалар белән эш | 27.09 |
| 17 | С.т.у дәресе. Татар халык әкиятләре | Әкият белән танышу, сорауларга җавап бирү | 30.09 |
| 18 | Монологик сөйләм үстерү "Яхшы сүз жанга рәхәт” | Лексик күнекмәләрне сөйләмдә дөрес куллану, хикәя төзи белү | 1.10 |
| 19 | Мәсәл. Иван Крыловның “Карга белән Төлке” мәсәле | Күзгә матурлыкны күрә, соклана белү хисе тәрбияләүгә әңгәмә | 3.10 |
| 20 | Мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар | Күплек сан, килеш, юклык, зат-сан кушымчаларын дөрес куллана белү | 4.10 |
| 21 | Мәҗит Гафури мәсәлләре. “Чикерткә белән Кырмыска”, “Тавык белән Үрдәк” | Сәнгатле уку конкурсы<br>Диалог төзү | 7.10 |
| 22 | Синоним һәм антонимнар | Синоним һәм антонимнарны аерырга өйрәнү, әһәмиятен аңлау, сүзлек запасын баету | 8.10 |
| 23 | Габдулла Тукай. “Яшь агач” әсәре | Укыган текстның мәгънәсен аңлау | 10 |
| 24 | Омонимнар. Сүзлекләр | Омонимнарны сөйләмдә куллану, сүзлекләрнең төрләре турында мәгълүмат бирү | 11.10 |
| 25 | Әхмәт Исхак. “Карт имән белән яшь егет» | Туган як табигатенә сак караш тәрбияләү | 14 |
| 26 | Алмашлыклар. | Зат, сорау алмашлыкларын сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнү | 15.10 |
| 27 | Кабатлау. Белемнәрне тикшерү | Тест эшләү | 17 |
| 28 | Фигыль | Боерык, хикәя фигыльләрне аырырга, сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнү | 18.10 |
| 29 | Г.Тукай “Ай һәм Кояш”, “Фатыйма белән Сандугач”. | Сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру. Рольләргә бүлеп уку. | 21 |
| 30 | Хикәя, өндәү, сорау җөмләләр | Җөмләләрне дөрес интонация белән уку, җөмлә азагына тиешле тыныш билгесен кую күнекмәләре | 22.10 |
| 31 | Автор әкиятләре. Г.Тукай «Шүрәле” әкияте. | Сәнгатьле уку. Сүзлек байлыгын арттыру. Дуслык хисе тәрбияләү. | 24 |
| 32 | Контроль диктант | Җөмләдә ия белән хәбәрне дөрес билгеләү | 25.10 |
| 33 | Автор әкиятләре. | Сәнгатьле уку. Сүзлек байлыгын | 28.10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Г.Тукайның «Шүрәле” әкияте | арттыру. Рәсем ясау | |
| 34 | Җөмләнең баш кисәкләре | Лексик-грамматик күнекмәләрне камилләштерү | 29.10 |
| 35 | Мәҗит Гафури. “Болын” шигыре , Муса Җәлил. “Яңгыр” шигыре | Уку күнекмәләрен яхшырту, табигатькә сак караш тәрбияләү | 7.11 |
| 36 | Монологик сөйләм үстерү. "Гөлләр - тормыш яме" | Лексик күнекмәләрне сөйләмдә дөрес куллану, хикәя төзи белү | .8.11 |
| 37 | Сынлы сәнгать музеенда.<br><br>Ф.А.Васильев – пейзажист. “Яңгыр алдыннан” картинасы | Картина буенча эшләү | 11.11 |
| 38 | Янгырау, саңгырау авазларга беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше | Янгырау, саңгырау тартыкка беткән исемнәргә тиешле кушымчалар ялгый белү күнекмәләре | 12.11 |
| 39 | Муса Җәлил “Чишмә” шигыре | Текст белән танышу. Әби-бабайларга карата хөрмәт хисе тәрбияләү. | 14 |
| 40 | Янгырау, саңгырау авазларга беткән исемнәрнең килеш белән төрләнеше | Янгырау, саңгырау тартыкка беткән исемнәргә тиешле кушымчалар ялгый белү күнекмәләре таблиа белән эш | 15.11 |
| 41 | Абдулла Алиш. “Койрыклар” әкиятен | Әкиятләр сөйләү,анализ ясау фикер алышу,мәгълүмат алу. | 18 |
| 42 | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше, сөйләмдә дөрес кулланылышы | Килешләрне яттан белү, кушымчаларны сөйләмдә дөрес куллану | 19.11 |
| 43 | Абдулла Алиш. “Койрыклар” әкияте өйрәнүне йомгаклау | А.Алиш турында бе-лемнәрне ту-лыландыру. Әсәр белән танышу. Сүз-лек запасын баету. | 21 |
| 44 | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше | Тартым кушымчаларын дөрес куллану, кушымчаларның ялганыш үзенчәлекләре | 22.11 |
| 45 | | | |
| 46 | Исемгә морфологик анализ ясау | Морфолгик анализ ясау күнекмәләре формалаштыру | 26.11 |
| 47 | Сынлы сәнгать музеенда.<br><br>Ф.А.Васильев – пейзажист. “Юеш болын” картинасы | Бәйләнешле сөйләм үстерү | 28.11 |
| 48 | Исемгә морфологик анализ ясау | Морфолгик анализ ясау күнекмәләре формалаштыру | 26.11 |
| 49 | Нәби Дәүли. “Бала болыт” әсәре | Сөйләм төзергә өйрәнү. Әхлак тәрбиясе турында сөйләшү. | 2.12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 50 | Сыйфатның дәрәҗә формалары. Гади дәрәҗә | Гади дәрәҗәдәге сыйфатларны сөйләмдә дөрес куллануга күнегүләр карточкалар | 3.12 |
| 51 | Рәшит Бәшәр. “Сандугачлы ак инеш” | Әсәре белән танышу. Табигатькә сак караш тәрбияләү | 5.12 |
| 52 | Чагыштыру дәрәҗәсе | Чагыштыру дәрәҗәсе кушымчаларын кулланып, җөмләләр төзү | 6.12 |
| 53 | Гәрәфи Хәсәнов. “Кышкы урман” хикәясе | Язучы турында белешмә алу. Әсәре белән танышу. | 9 |
| 54 | Кимлек дәрәҗәсе | Кимлек дәрәҗәсенә дөрес кую, сыйфатлар кулланып, җөмләләр төзү. | 10.12 |
| 55 | Сынлы сәнгать музеенда.<br><br>И.Э.Грабарь. “Февраль зәңгәрлеге” | Экскурсия үткәрү | 12 |
| 56 | Сыйфатларны кабатлау | Сыйфат турында белемнәрне камилләштерү, гомумиләштереп кабатлау | 13.12 |
| 57 | Фәнис Яруллин. “Иң бәхетле төн” әкияте | Аңлап уку күнекмәләре булдыру | 16 |
| 58 | Татар телендә саналмыш | Саналмышларны дөрес билгеләргә өйрәнү | 17.12 |
| 59 | Сания Әхмәтҗанова. “Саклыйк, әйдә, җир-ананы” шигыре | Аңлап уку күнекмәләре булдыру | 19 |
| 60 | Контроль диктант | Белемнәрне тикшерү | 20.12 |
| 61 | Бүлекне кабатлау | Мөстәкыйль эшләү | 23.12 |
| 62 | Сан буенча алган белемнәрне гомумиләштереп кабатлау | Грамматик күнекмәләрне камилләштерү | 24.12 |
| 63 | Проект эше | Проект ясау | 9.01 |
| 64 | Тәртип саны | Хаталарны кисәтү, төзәтү, аңлауга схемалар | 10.01 |
| 65 | Балачак әдипләре | Язучылар турында сөйләшү | 13.01 |
| 66 | Тартым алмашлыклары | Тартым алмашлыкларын сөйләмдә дөрес куллану | 14.01 |
| 67 | Шәүкәт Галиев “Камырша” | Шагыйрь турында белешмә бирү. Аңлап уку. | 16 |
| 68 | Күрсәтү алмашлыклары | Предметка һәм затка күрсәтә | 17.01 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | торган алмашлыкларны сөйләмдә дөрес куллануга күнегүләр | |
| 69 | Шәүкәт Галиев “Күршеләрнең алмасы”, “Минем абый шигырь ятлый”, “Куркыныч хәбәр” шигырьләре | Укыган текстның мәгънәсен аңлау. Сүзлек өстендә эшләү практик эш | 20 |
| 70 | Фигыль. Боерык фигыльләр | Фигыль турында белемнәрне камилләштерү; боерык фигыльләрнең белдерелүе, юклык формасы таблиа белән эш | 21.01 |
| 71 | Роберт Миңнуллин шигыре “Әни, мин көчек күрдем” | Шагыйрь турында белешмә бирү. Аңлап уку.Сорауларга җавап бирү. | 23 |
| **72** | Боерык фигыльнең зат - сан белән төрләнеше | Боерык фигыльләрне зат-сан белән дөрес төрләндерү, сөйләмдә дөрес куллану | 24.01 |
| **73** | “Спортның яңа төре” шигыре | Әсәрнең эчтәлеген сөйләү. | 27 |
| **74** | Хәзерге заман хикәя фигыль | Хәзерге заман кушымчаларын дөрес кулланып, җөмләләр төзү. | 28.01 |
| **75** | Ш.Галиев һәм Р.Миңнуллин китаплары Сыйныфтан тыш уку | Укыган текстның мәгънәсен аңлау | 30.01 |
| **76** | Үткән заман хикәя фигыль | Үткән заман кушымчаларын дөрес куллана белү | 31.01 |
| **77** | Бүлекне кабатлау | Сорауларга җавап бирү. | 3.02 |
| **78** | Хикәя фигыльнен барлык заман формаларын зат-сан белән төрләндерү | Зат-сан кушымчаларын дөрес куллану, җөмләләр төзү | 4.02 |
| **79** | Хакимҗан Халиков шиг. “Дәү әти”, “Вакыты тар” | Герой турында сөйләшү. | 6.02 |
| **80** | Фигыль буенча алган белемнәрне гомумиләштереп кабатлау | Грамматик күнекмәләрне камиләштерү | 7.02 |
| **81** | “Чыпчык баласы Чырчыр турында әкият” | Укыган текстның мәгънәсен аңлау | 10 |
| **82** | Бәйлекләр. Бәйлек сүзләр | Бәйлек һәм бәйлек сүзләрне аерырга өйрәнү, сөйләмдә дөрес куллану | 11.02 |
| **83** | Сынлы сәнгать музеенда. Ф.Х.Якуповның “Аналар җәе” картинасы | Әниләргә карата мәхәббәт хисе тәрбияләү | 13 |
| **84** | Тәрҗемә итү, күнегүләр эшләү | Ике яклы тәрҗемә күнегүләре | 14.02 |
| **85** | Сәхнә әсәрләре, уеннар. “Нинди кош?” | Сәнгатьле уку. Сорауларга җавап бирү. | 17 |
| **86** | Сүзтезмә һәм җөмлә | Иярүче һәм ияртүче сүзләрне аера белү, җөмлә чикләрен | 18.02 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | билгели белү | |
| **87** | Фәнис Яруллин шиг. “Ап-ак иткән”, “Бияләй” | Сәнгатьле уку күнекмәләрен камилләштерү | 20 |
| **88** | Сүзтезмә һәм җөмлә | Ияртүче һәм ияртүче сүзләрне аера белү, җөмлә чикләрен билгели белү | 21.02 |
| **89** | Ф.Яруллин “Юылмас хурлык”хикәясе | Укыган текстның мәгънәсен аңлау | 24 |
| **90** | Сочинениеләрне анализлау | Хаталарны кисәтү, төзәтү, аңлау | 25.02 |
| **91** | С.т.уку дәресе.<br><br>Китап киштәсе. Х.Халиков һәм Ф.Яруллин китаплары | Шагыйрьләр турында белешмә бирү. Сәнгатьле уку. | 27.02 |
| **92** | Җөмләнең баш кисәкләре. Ия. | Җөмләләрдән ияләрне табу | 28.02 |
| **93** | С.т.уку дәресе.<br><br>Китап киштәсе. Х.Халиков һәм Ф.Яруллин китаплары | Шагыйрьләр турында белешмә бирү. Сәнгатьле уку. | 27.02 |
| **94** | Исемнәр һәм зат алмашлыкларының җөмләдә ия булып килүе | Күнегүләр эшләү, практик эш схемалар | 4.03 |
| **95** | Роза Хафизова. “Күгәрчен һәм малай” | Сәнгатьле уку. Сүзлек байлыгын арттыру. Дуслык хисе тәрбияләүгә уеннар. | 6.03 |
| **96** | Җөмләнең баш кисәкләре. Хәбәр. | Хәбәрләрне дөрес билгеләү | 7.03 |
| **97** | Сәрвәр Әдһәмова “Дуслар” хикәсе | Сәнгатьле уку. Сүзлек байлыгын арттыру. Дуслык хисе тәрбияләү. | 10 |
| **98** | Боерык һәм хикәя фигыльләрнең җөмләдә хәбәр булып килүе | Грамматик күнекмәләрне камилләштерү, җөмләләр төзи белү | 11.03 |
| **99** | Әхсән Баян. “Эт янында тиеннәр” | Сәнгатьле уку.конкурсы | 13 |
| **100** | Монологик сөйләм үстерү | Лексик күнекмәләрне куллануга күнегүләр | 14.03 |
| **101** | Дәрҗия Аппакова “Шыгырдавыклы башмаклар” хикәясе | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү | 17.03 |
| **102** | Хаталар өстендә эш | Хаталарны кисәтү, төзәтү, аңлау | 18.03 |
| **103** | Михаил Зощенко «Мескен Федя» | Бәйләнешле сөйләм телен үстерү | 3.04 |
| 104 | Җыйнак җөмләләр | Җыйнак җөмләләр төзи белүгә практик эш | 1.04<br>4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 105 | Резеда Вәлиева шигыре “Җиңү көнендә” | Сугышка багышланган шигыр.уку. Туган якка мәхәббәт, горурлык хисе тәрбияләү | 7.04 |
| 106 | Җәенке җөмләләр | Җәенке җөмләләр төзү, җыйнак җөмләне җәенке җөмләгә әйләндерү | 8.04 |
| 107 | Сынлы сәнгать музеенда. И.В.Рәфыйковның “Сугыш еллары” картинасы | Картина буенча әңгәмә | 10 |
| 108 | Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч. | Җөмләдә аергычларны билгели белү, җөмләләр төзү | 11.04 |
| 109 | Нәбирә Гыйматдинова “Сертотмас кәҗә” | Уку, сөйләү | 14 |
| 110 | Аергычның сыйфат, сан белән белдерелүе | Сыйфат, сан төркемнәрен аергыч булырлык итеп җөмләләр төзү | 15.04 |
| 111 | “Әллә каян күренеп тора”. Виктор Голявкин | Яраткан әкиятләр турында сөйләшү | 17 |
| 112 | Аергычның сыйфат, сан белән белдерелүе | Сыйфат, сан төркемнәрен аергыч булырлык итеп җөмләләр төзү | 18.04 |
| 113 | “Сәгать ярдәм итте”. Юрий Ермолаев | Уку, сөйләү | 21 |
| 114 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре | Тиңдәш кисәкләрне таба белү | 22.04 |
| 115 | Б.с.ү. “Балачакның кызыклы уеннары” | Төрле кызыклы уеннар уйнау | 24 |
| 116 | Җөмләнең иярчен кисәкләре янында җыючы һәм каршы куючы теркәгечләр | Теркәгечләрне дөрес кулланып, җөмләләр төзү буенча практик эш | 25.04 |
| 117 | Бүлекне кабатлау | Сорауларга дөрес җавап бирү буенча ярыш конкурс | 28.04 |
| 118 | Эндәш сүзләр. Алар янында тыныш билгеләре | Эндәш сүзләрне дөрес куллану, алар янына тиешле тыныш билгеләрен куя белү | 29.04 |
| 119 | “Чыдам кургашын солдат” әкияте. Г.-Х.Андерсен | Уку, сөйләү әдәби китап уку | 1.05 |
| 120 | Эндәш сүзләр. Алар янында тыныш билгеләре | Эндәш сүзләрне дөрес куллану, алар янына тиешле тыныш билгеләрен куя белү күнегүләре практик эш | 2.05 |
| 121 | “Гулливер сәяхәте” | Мәзәкләр белән танышу, уку. | 5.05 |
| 122 | Җөмләгә синтаксик анализ ясау | Грамматик күнекмәләр | 6.05 |
| 123 | “Шүрәле малае” (әкият-пьеса) | Уку, сөйләү | 8 |
| 124 | Бүлекне гомумиләштереп кабатлау | Грамматик күнекмәләр | 9 |
| 125 | Бүлекне кабатлау | Уку, сөйләү, дәреслек белән эш | 12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 126 | Контроль диктант | Грамматик биремле диктант язу | 13 |
| 127 | “Шүрәле җыры”.<br><br>Зиннур Хөснияр. | Сәнгатьле уку, анализ ясау | 15 |
| 128 | Кабатлау. Исем, сыйфат, сан. | Грамматик биремнәр | 16.05 |
| 129 | Ел буена үткәннәрне кабатлау. Викторина. “Шагыйрьләр иҗатын беләбезме?” | Ел буена үткәннәрне кабатлау , викторинаүткәрү | 19.05 |
| 130 | Кабатлау . Сүзтезмә һәм җөмлә. | Грамматик күнекмәләрне камилләштерү | 20.05 |
| 131 | Кабатлау. Үткәннәрне йомгаклау | | 23.05 |
| 132-136 | Кабатлау. Җөмлә кисәкләре. | Грамматик күнекмәләрне камилләштерү | 25.05 |

пронумеровано, прошнуровано
и скреплено печатью четырнадцать листов

Учитель ---------------- И.Х.Замалиева

МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«Алексеевская средняя общеобразовательная школа №2 с углубленным изучением отдельных предметов»
ИНН 1605001185